| | | |
|---|---|---|
| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 октябрь, 2024 ел № 37/5

Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/7 номерлы Карары белән расланган «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү системасы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең хезмәт өчен түләве бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләп чыгарыла торган хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 ел, 14 июнь, 477 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 6 маендагы 300 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Методик тәкъдимнәр турында» 2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 2 августындагы под – 1381/24 номерлы боерыгы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2022 елның 13 апрелендәге 14/7 номерлы Карары белән расланган «Мәгълүмати-методик үзәк» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү системасы турында нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2023 елның 29 мартындагы 22/7 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Учреждение хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы үткән затка “бакалавр”, “магистр” яисә “дипломлы белгеч” квалификациясе бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 18 405,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 18 410,0 |
| Җитәкче вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Учреждение директоры | | | 18 550,0 |

2) 12 пунктның 3 пунктчасындагы унынчы абзацында «Мәгарифтәге казанышлары өчен» сүзләреннән соң «, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклап калган һәм үстергән өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе, «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» аерымлык билгесе, «Мактаулы остаз» аерымлык билгесе» сүзләрен өстәргә.;

3) 30 пунктта «бухгалтер,», «биналарга һәм корылмаларга комплекслы хезмәт күрсәтү буенча эшче;» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Учреждение хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары):

| Бердәм тариф челтәренә түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тарифлы ставкалар (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 19 242 |
| 2 | 1,0126 | 19 484 |
| 3 | 1,0256 | 19 735 |
| 4 | 1,0381 | 19 975 |
| 5 | 1,0521 | 20 245 |
| 6 | 1,0656 | 20 504 |
| 7 | 1,0802 | 20 785 |
| 8 | 1,0942 | 21 055 |
| 9 | 1,1083 | 21 326 |
| 10 | 1,1233 | 21 615 |
| 11 | 1,1379 | 21 895 |
| 12 | 1,1535 | 22 196 |
| 13 | 1,1691 | 22 496 |
| 14 | 1,1846 | 22 794 |
| 15 | 1,2008 | 23 106 |
| 16 | 1,2174 | 23 425 |
| 17 | 1,2340 | 23 745 |
| 18 | 1,2512 | 24 076 |

Әлеге Нигезләмәнең 30 пунктында каралган учреждениеләр хезмәткәрләренә стимуллаштыру түләүләре локаль норматив актлар белән расланган эшчәнлек критерийлары нигезендә билгеләнә.

Премия түләүләре һәм керем китерә торган эшчәнлектән алынган акчалар исәбеннән түләүләр учреждениеләрнең локаль актлары нигезендә түләнә..».

2. Әлеге Карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 сентябреннән  соң барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

3.Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев